КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 декабрь г.Казань № 1290

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан бирелә торган бюджет кредитлары гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган инфраструктура проектларын сайлап алу кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясендә төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 14 июлендәге 1189 номерлы карары нигезендә сайлап алынган Татарстан Республикасының инфраструктура проектлары кысаларында гамәлгә ашырыла торган чараларның детальләштерелгән исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан алынган бюджет кредитларын Россия Федерациясе субъектларына бирү, алар тарафыннан файдалану һәм кире кайтару кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 14 июлендәге 1190 номерлы карары белән расланган Инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан алынган бюджет кредитларын Россия Федерациясе субъектларына бирү, алар тарафыннан файдалану һәм кире кайтару кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу механизм карарга теркәлгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан бирелә торган бюджет кредитлары

гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган инфраструктура проектларын сайлап алу кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясендә төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 14 июлендәге 1189 номерлы карары нигезендә сайлап алынган Татарстан Республикасының инфраструктура проектлары кысаларында гамәлгә ашырыла торган чараларның детальләштерелгән исемлеген (алга таба шул ук эзлеклелектә – инфраструктура проектлары, детальләштерелгән исемлек) расларга.

2. Инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы арасында Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча төзелә торган килешү нигезендә башкарыла.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

детальләштерелгән исемлек нигезендә чараларны тормышка ашыруны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне;

бюджет кредиты бурычларын тулысынча каплап бетергәнче, квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында каралган максатлар өчен инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан алынган бюджет кредиты (алга таба – бюджет кредиты) акчасын җибәрү турындагы хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне;

бу карарны, аңа кертелә торган үзгәрешләрне Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм Федераль казначылыкка җибәрүне.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 25 енә кадәр, түбәндәгеләрне кертүне тәэмин итәргә:

инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру турындагы белешмәләрне Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына;

бюджет кредиты бурычларын тулысынча каплап бетергәнгә кадәр Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатлар өчен бюджет кредиты акчасын җибәрү турындагы хисапны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгына.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 27 декабрь, 1290 нчы
карары белән расланды

## Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан бирелә торган бюджет кредитлары гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган инфраструктура проектларын сайлап алу кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясендә төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 14 июлендәге 1189 номерлы карары нигезендә сайлап алынган Татарстан Республикасы инфраструктура проектлары кысаларында гамәлгә ашырыла торган чараларның детальләштерелгән исемлеге

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Инвестиция проекты исеме | Инфраструктура проекты исеме | Инфраструктура объекты исеме/ объект адресы/ объектның проект куәте | Инфраструктура төре | Эшләр төре | Гамәлгә ашыру сроклары | | Финанслау чыганаклары | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | башлану датасы | тәмамлану датасы | барысы | шул исәптән | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | ИБК[1], мең сум | шул исәптән | | | | | | федераль бюджет акчасы, мең сум | берләштерелгән төбәк бюджеты, мең сум | бюджеттан тыш чыганаклар, мең сум |
| | | | | | | | | | | | 2021 ел, мең сум | 2022 ел, мең сум | 2023 ел, мең сум | 2024 ел, мең сум | 2025 ел, мең сум | 2025 елдан соң, мең сум | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| 1. | Казан ш. | 1 класслы гомумшәһәр әһәмиятендәге магистраль урамыннан транспорт йөрү мөмкинлеген | Вознесение тракты. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында Гвардия урамыннан | Вознесение тракты. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында Гвардия урамын- | транспорт | төзелеш | 2021 ел | 2024 ел | 13 410 067,05 | 6 103 600,0 | 0,0 | 6 103 600,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 5 004 974,3 | 500 000,0 | 1 801 492,75 |

[1]ИБК – инфраструктура бюджет кредиты.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | тәэмин итеп, территорияләрне үстерү (торак төзелеше) (Вознесение тракты) | Җиңү проектспектына кадәрге участокны төзү | нан Җиңү проспектына кадәрге участокны төзү / Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге участок/- озынлыгы – 3,852 км | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | | Казан шәһәрендә Горький шоссе урамы һәм Осиново урамы буенча транспорт йөрү мөмкинлеген тәэмин итеп, территорияләрне үстерү (торак төзелеше) | Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районындагы Осиново урамын реконструкцияләү | Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районындагы Осиново урамын реконструкцияләү/ Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Осиново урамы/ озынлыгы – 1,4 км | транспорт | реконструкцияләү | 2022 ел | 2022 ел | 1 219 200,0 | 1 219 200,0 | 0,0 | 1 219 200,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| | | | Казан шәһәренең Ки- | Казан шәһәренең Киров районы- | транспорт | реконструкцияләү | 2022 ел | 2025 ел | 14 539 036,0 | 3 098 638,0 | 0,0 | 3 098 638,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 11 440 398,0 | 0,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ров районындагы Горький шоссесын реконструкцияләү. Болотников урамы, Фрунзе урамы, Горький шоссесы урамы, Залесная урамы, Музыкальная урамыннан М-7 «Волга» федераль әһәмияттәге автомобиль юлына кадәрге участок | ныңдагы Горький шоссесын реконструкцияләү. Болотников урамы, Фрунзе урамы, Горький шоссесы урамы, Залесная урамы, Музыкальная урамыннан М-7 «Волга» федераль әһәмияттәге автомобиль юлына кадәрге участок /Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Болотников урамы, Фрунзе урамы, Горький шоссесы урамы, Залесная урамы, Музыкальная урамыннан М-7 «Волга» федераль әһәмият- | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тәге автомобиль юлына кадәрге участок/ озынлыгы – 11,557 км | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | Проект буенча барысы | х | х | х | х | х | х | 15 758 236,0 | 4 317 838,0 | 0,0 | 4 317 838,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 11 440 398,0 | 0,0 |
| Барысы | | | х | х | х | х | х | х | 29 168 303,05 | 10 421 438,0 | 0,0 | 10 421 438,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 5 004 974,3 | 11 940 398,0 | 1 801 492,75 |

---